Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел №112

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 58 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 58 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 62 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 11 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 55 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 60 номерлы, 2024 елның26 июнендәге 103 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 19 167 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 18 607» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (12 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 19 173 |
| Башлык урынбасары | 13 991» |

2. Әлеге карарны Бишмунча авылы, Совет ур., 57а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга ур.,.26а йорт, Ак-Чишма авылы, Ак-Чишма ур.,1 йорт, Бахчасарай авылы, Җиләкле ур., 1 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы М.Т.Мөбәрәкшин